МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

15.07.2025 Казан ш. 2391-р

Бүлгеч газүткәргечнең саклау зонасын үзгәртү һәм Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Татарстан Республикасы Казан шәһәре территориясендә газ бүлү челтәрләренең (газүткәргечләрнең) саклау зоналарын билгеләү турында” 19.12.2015 № 3233-р карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Җир Кодексының 56, 106 статьяларына, «Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы № 69-ФЗ Федераль законга, «Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» 13 июль 2015 ел № 218-ФЗ Федераль законның 32 ст., Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләрен раслау турында», 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләренә туры китереп һәм «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ мөрәҗәгате һәм ««Основание» кадастр үзәге» ҖЧҖ әзерләгән документациягә туры китереп, «Татарстан Республикасы пространство мәгълүматы фонды» ДБУ (20.06.2025 № 01А-04/1154) хатын истә тотып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.08.2007 ел, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмәсенә таянып:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Татарстан Республикасы Казан шәһәре территориясендә газ бүлү челтәрләренең (газүткәргечләрнең) саклау зоналарын билгеләү турында”

19.12.2015 № 3233-р карары (алга таба - № 3233-р Карар) белән урнаштырылган, «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ милкендәге, “Казан шәһәре” муниципаль берәмлеге территориясендә булган 16:50:220525:393, 16:50:220525:32 кадастр номерлы җир кишәрлекләрендәге демонтаж сәбәпле, саклау зонасына, җир өсте һәм җир асты объектлары чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегенә туры китереп, инвентарь номеры 19036, реестр номеры 16:50-6.4039 булган бүлгеч газүткәргечнең саклау зонасына үзгәртергә. Газ бүлү газүткәргеченең саклау зонасы гомуми мәйданы (68228 +/- 91) кв.м булып, 18 047 м озынлыкны тәшкил итә.

2. Инвентарь номеры 19036 булган газ бүлү челтәренең эксплуатация срогында өлешчә яки тулысынча газүткәргечнең саклау зонасына туры килгән әлеге карарның 1 нче пунктында күрсәтелгән җир кишәрлекләренә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләрендә каралган чикләүләр (йөкләүләр) кертергә.

3. Территорияне куллануның аерым шартлары булган зоналар чикләре урнашуның текстлы һәм график тасвирламасында күрсәтелгән белешмәләргә, газүткәргеч чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге нигезендә № 3233-р карарына (Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 24.01.2017 № 107-р, 22.06.2017 № 1378-р, 13.07.2017 № 1608-р, 29.08.2017 № 1977-р, 28.09.2017 № 2191-р, 22.09.2017 № 2155-р, 22.08.2018 № 2563-р, 31.08.2018 № 2653-р, 05.12.2018 № 4140-р, 25.06.2019 № 1970-р, 07.08.2019 № 2419-р, 05.11.2019 № 3520-р, 21.01.2020 № 117-р, 25.10.2021 № 3236-р, 28.12.2021 № 4111-р, 14.06.2022 № 1741-р, 22.08.2022 № 2447-р, 05.07.2023 № 1849-р, 06.12.2023 № 3416-р, 14.03.2024 № 621-р, 17.04.2024 № 1078-р, 23.10.2024 № 3353-р, 27.11.2024 № 3845-р, 27.02.2025 № 658-р, 19.03.2025 № 877-р, 02.04.2025 № 1051-р, 11.07.2025 № 2339-р) карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Казан ш. (Авиатөзелеш, Вахитов, Киров, Мәскәү, Яңа Савин, Идел буе, Совет районнары) территориясендәге 1452,66419 км озынлыктагы, ЭПУ «Казаньгоргаз»ның әлеге карарның 1 нче кушымтасында күрсәтелгән инвентарь номерлы газ бүлү челтәрләренең (газүткәргечләр) 5,4223663 кв.км мәйданны тәшкил иткән саклау зоналары чикләрен «Рубикон» кадастр үзәге» ҖЧҖ, «РКЦ «Земля» АҖ, «Күчемсез милек кадастры» ҖЧҖ, «ГеоПроект» ҖЧҖ, «Казан ш.нең җир-инвестиция агентлыгы» ҖЧҖ, «АллЮр» ҖЧҖ, «Основание» кадастр үзәге» ААҖ, «Бәяләү һәм кадастр үзәге» ҖЧҖ, «КАДАСТР» ҖЧҖ тарафыннан әзерләнгән җир өсте һәм җир асты

объектларының саклау зоналарына картасында (планында) булган белешмәләр нигезендә урнаштырырга.»;

1 нче кушымтада инвентарь номеры 19036булган газүткәргечкә туры килгән юлны әлеге карарга кушымтадагы редакциядә бәян итәргә (бастыру каралмаган).

**Министр** **А.Р.Кадыйров**